РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**10 март 2023 ел** **Чистай шәһәре** **№ 21/5**

Чистай муниципаль районы Советының 2022 елның 17 августындагы «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 16/1 номерлы Татарстан Республикасы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2023 елның 06 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау турында”гы 2022 елның 17 августындагы 16/1 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктын өстәргә:

«1.1. Депутат алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез район Советының утырышларында катнашмаган очракта, район Советы карары белән депутат вәкаләтеннән вакытыннан алда туктатыла.»;

1.2. 3 статьяның 3 пунктында, 18 статьяның 1 пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга».

1.3. 17 статьяның 1 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ

булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне гамәлдәге законнар нигезендә тапшырырга.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чистай муниципаль
районы Башлыгы Д.А. Иванов